СОВЕТ КАТМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.17, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 7-7 «03 » март 2016 ел

2016 елның 28 февралендә референдумда
кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 No 23-ТРЗ Җирле референдум турында, 2016 елның 28 февралендә референдум нәтиҗәләре нигезендә:

«2015 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гражданнардан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, Россия армиясе сафларына срочная хезмәткә чакырылган, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануын муниципаль контрольдә тотуны гамәлгә ашыру:

Катмыш авылы, Баскан авылы, Еникей Чишмә авылы -56, 0 мең сум җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау.

торак пункт чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

Еникей Чишмә торак пунктының су күтәрү манарасын төзекләндерү (каплау).- 12,0 мең сум

торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керүен тәэмин итү:

Катмыш торак пунктында, Баскан торак пунктында Җиңү һәм ял паркларын саклау, Баскан торак пунктында "Тегермән чишмәсе" н ремонтлау-25,0 мең сум.

- торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру Ениикей Чишмә торак пункты Катмыш торак пункты, Баскан торак пункты 12,0 мең сум.

Әйе / Юк»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында»2016 елның 29 февралендәге 34 номерлы карарын теркәү.

2.Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану юнәлешләрен һәм күләмнәрен кушымта буенча билгеләргә.

3.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru).

Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе .Г. Габидуллин

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советының 3 март, 2016 ел, № 7-7 карарына
КУШЫМТА

# Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану юнәлешләре һәм күләмнәре

| N т/п | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең атамасы | Шул исәптән планлаштырылган чаралар | чараларны гамәлгә ашыруга акча күләме, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануын муниципаль контрольдә тотуны гамәлгә ашыру. | Катмыш торак пункты, Баскан торак пункты, Еникей Чишмә торак пункты җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау | 56,0 |
| 2 | торак пункт чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру | Еникей Чишмә торак пунктының су күтәрү манарасын төзекләндерү(каплау). | 12,0 |
| 3 | торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керүен тәэмин итү; | Катмыш торак пунктында, Баскан торак пунктында Җиңү ял паркларын саклау. Баскан торак пунктында "Тегермән чишмәсе" чишмәсен ремонтлау | 25,0 |
| 4 | торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү; | Янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру Аникей Чишмә торак пункты Катмыш торак пункты, Баскан торак пункты | 12,0 |
| **Барлыгы** | | | 105,0 |